**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 сентябрь № 683

г. Казань

Татарстан Республикасында калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схеманы раслау турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең территориаль схемалары составына һәм эчтәлегенә таләпләрне раслау турында» 2016 ел, 16 март, 197 нче карары, Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасында калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схеманы (алга таба – Территориаль схема) расларга.
2. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документларын, муниципаль берәмлекләр территорияләрен чистартуның генераль схемаларын әлеге карар белән расланган Территориаль схеманы исәпкә алып тәгаенләштерергә тәкъдим итәргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\683.docx